Республика Татарстан СОВЕТ ЯНУРУСОВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ САРМАНОВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

САРМАН МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫҢ Татарстан Республикасы ЯНУРЫС ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

423370, Татарстан Республикасы, Сарман районы, Янурыс авылы, Ленин ур., 43 а, тел.4-10-19ИНН 1636001403 КПП 163601001 Р/С 40204810500057002ЗОГРН 1031604000757 ОКАТО 92253884000

РЕШЕНИЕ

КАРАР

«05 »июнь, 2017ел. №9

2014 елның 26 апрелендәге 8 номерлы Янурыс авыл җирлеге советы карары белән расланган Сарман муниципаль районының «Янурыс авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәт турында» нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

Сарман муниципаль районының «Янурыс авыл җирлеге» муниципаль хезмәт турында нигезләмәне «Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» Федераль законның 21 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» 2017 елның 1 маендагы 90-ФЗ номерлы Федераль законга туры китерү максатларында Янурыс авыл җирлеге карар итте

1. 2014 елның 26 апрелендәге 8 нче карары белән расланган Сарман муниципаль районының «Янурыс авыл җирлеге» МБ муниципаль хезмәте турында нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 5 бүлекнең 5.4.пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Ел саен төп түләүле отпуск муниципаль хезмәткәргә 30 календарь көн дәвамлылыгы белән бирелә».

2) 5 бүлекнең 5.5.пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Ел саен өстәмә түләүле отпусклар муниципаль хезмәткәргә тиешле еллар эшләгән (10 календарь көннән дә артык булмаган дәвамлылыгы) өчен, шулай ук федераль законнарда һәм Россия Федерациясе субъекты законнарында каралган очракларда бирелә. Нормалаштырылмаган хезмәт көне билгеләнгән муниципаль хезмәткәргә нормалаштырылмаган хезмәт көне дәвамлылыгы өч календарь көнгә тигез еллык өстәмә түләүле отпуск бирелә».

2.Әлеге карарны «Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталы» (PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм «Сарман муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең рәсми сайтында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга.

3.Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Сарман муниципаль районының Янурыс авыл җирлеге башлыгына йөкләргә.

Сарман районы
Янурыс авыл җирлеге
башлыгы                                                    А. А. Мөхәммәдиева